44. Ibrahimov, G. *Kətychelər* [Shepherds]. URL: https://www.antat.ru/ru/iyli/Ibragimov%20-%20130/Kotucheler.pdf (accessed: 02.10.25). (In Tatar)

45. Kazakova, M. V. (2020). *Problema bilingvizma v poehzii A. I. Mishina 1970-1980-kh gg.: avtoreferat dis. ... kandidata filologicheskikh nauk: 10.01.02* [The Problem of Bilingualism in A. Mishin's Poetry of the 1970s–1980s: Ph.D. Thesis Abstract]. Moscow, 25 p. (In Russian)

46. Zaripova-Chetin, Ch. (2003). *Problema demonizma v tvorchestve S. Ramieva v kontekste vostochno-evropeiskoi ehstetiki* [The Problem of Demonism in the Works of S. Ramiev in the Context of Eastern European Aesthetics]. 175 p. Kazan', "Master-Lain". (In Russian)

47. Zaripova-Chetin, Ch. (2005). *"Uilasam ui, syzlyi kyңel, syzlyi җan" S. Rəmievneң tormysh yuly həm iҗatyna karata yaңa məg"lymatlar* ["When I Think about It, My Heart Aches, My Soul Aches". New Information about S. Ramiev's Life and Work]. (Fotorəsemnər belən). 202 p. Kazan, "Yaңalif" nəshriyat iorty. (In Tatar)

48. Zaripova Çetin, Ç. (2016). *Alimcan İbrahimov'un Eserlerinde Tatar, Başkurt ve Kazak Türklerinin Kültürel Değerleri* [Cultural Values of Tatar, Bashkir, and Kazakh Turks in the Works of Alimcan İbrahimov]. 369 p. Ankara, Bengü. (In Turkish)

49. Zaripova Çetin, Ç. (2020). *Alimcan İbrahimov* [Alimcan İbrahimov]. Âdemler. Araştırma-İnceleme-Metin. 169 p. Ankara, Bengü. (In Turkish)

50. İshaki, A. (2009). *Hikâyeler (Seçmeler)* [Stories (Selections)]. Çev. Çulpan Zaripova Çetin, Hayati Yılmaz. 182 p. Muğla, Muğla Üniversitesi Yayınları. (In Turkish)

51. Garipov, M. (2016). *Ebedi Aşk. Abdullah Tukay ile Zeytüne Mevlüdova Hikâyesi* [Eternal Love. The Story of Abdullah Tukay and Zeytüne Mevlüdova]. Çev. Çulpan Zaripova Çetin, Hayati Yılmaz. 103 p. Ankara, Bengü. (In Turkish)

52. İbrahimov, A. (2022). *Seçme Eserler* [Analects]. Çev. Çulpan Zaripova Çetin. 290 p. Ankara, Bengü. (In Turkish)

53. Mehdiyev, M. (2025). *Turnaların İndiği Yerde* [Where the Cranes Land]. Çev. Çulpan Zaripova Çetin. 305 p. Ankara, Bengü. (In Turkish)

54. Tatdzhy, M. (2021). *Yazyk lyubvi Yunus Ehmre. Zhizn' i tvorchestvo. Stikhotvoreniya* [The Language of Love by Yunus Emre. Life and Works. Poems]. 133 p. Ankara, Rukovodstvo tsentra kul'tury im. Atatyurka. (In Russian)

55. Karakhanly, Eh. Z. (2019). *Lyubov' prevyshe khramov* [Love Is above Temples]. 148 p. Baku, Muterdzhim. (In Russian)

56. *Islam cherez prizmu khadisov v 7 tomakh* (2021) [Islam through the Prism of Hadith in 7 Volumes]. T. 2, 3, 4. 488 p. Moscow, Dukhovnoe upravlenie musul'man Rossiiskoi Federatsii. (In Russian)

# ЧУЛПАН ЗАРИФ ИҖАТЫНДА БИЛИНГВИЗМ КАЛЫПЛАШУНЫҢ АЛШАРТЛАРЫ

**Айзирәк Наил кызы Гәрәева,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 йорт,
aizigarai@mail.ru

Чулпан Әфраим кызы Зарипова-Четин (әдәби тәхәллүсе Чулпан Зариф) – тумышы белән Татарстан Республикасының Арча районыннан. Казан дәүләт педагогика университетын тәмамлаган (1992) шагыйрә татар, төрек, рус телләрендә иҗат итә. Бүгенге көндә «Кояшка юл тота кәрваным» (2003), «Апельсиновая осень» («Әфлисун төсендәге көз», 2013), «Lacivərd Yuxular» («Зәңгәр төшләр», 2023) дип исемләнгән җыентыклар авторы. Шигъриятендә күңел лирикасы өстенлек ала. Чулпан Зарифның шигырьләре инглиз теленә, азәрбайҗан, башкорт, төркмән, чуваш һ.б. төрки телләргә тәрҗемә ителгән. Эзләнү барышында Чулпан Зариф иҗатында автор билингвизмы калыплашуының алшартлары, чыганаклары, әдәби алымнар ачыкланды.

**Төп төшенчәләр:** Татар әдәбияты, Чулпан Зариф, автор билингвизмы, әдәби билингвизм, икетеллелек

**Сылтама өчен:** Гараева А. Н. Чулпан Зариф иҗатында билингвизм калыплашуның алшартлары // Tatarica. 2026. № 1 (26). 71–90 б. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-25-1-71-90

## Кереш

Чулпан Әфраим кызы Зарипова-Четин (әдәби тәхәллүсе Чулпан Зариф) 1992 елда Казан педагогика университеты рус филологиясе факультетының Милли мәктәптә рус телен, әдәбиятын укыту бүлеген тәмамлый. 1999 елдан башлап, Төркиядә яши. Чулпан Зариф татар, рус һәм төрек телләрендә иҗат итә. Татарстанда һәм чит илдә ул талантлы шагыйрә, тәрҗемәче, әдәбият белгече, мөгаллим буларак танылу ала. Аның рус һәм төрек телләренә тәрҗемәдәге иҗаты яңа шигъри җәүһәрләр кебек кабул ителә. «Лингвистик мигрантлар» иҗатына фәндә төрле карашлар бар, әмма бу күренеш әлегәчә тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгән өлкә булып кала килә.

**Эзләнүнең максаты** – шагыйрәнең тәрҗемәи хәлендә аның иҗатындагы билингвизмга нигез булып торган алшартларны ачыклау.

Ч. Зарифның әдәби иҗатын өйрәнү мәдәниятара диалог контекстында аеруча әһәмияткә ия. Мондый әдәби текстларның филолог белгечләр өчен кыйммәтле чыганак булып торуын билгеләүче факторлар бар. Беренчедән, тәрҗемәче-шагыйрә иҗаты үзе үк телара һәм мәдәниятара багланышларның үзенчәлекле мисалы. Ч. Зариф поэзиясен өйрәнү автор билингвизмының башлангычын билгеләү һәм мәдәниятара бәйләнешләрнең шагыйрә иҗатында гәүдәләнеш табуын ачыклау мөмкинлеге бирә. Икенчедән, шагыйрәнең иҗаты – Төркиядәге бүгенге татар мөһаҗирләренең тормышы хакында кыйммәтле чыганак ул. Шигърияте аша әдибә чит илдә яшәүче татарларның хис-кичерешләрен, уй-фикерләрен ачык бәян итә, рухи дөньяларын таныта. Өченчедән, төрле мәдәниятләрне тоташтыручы шагыйрәнең иҗатын өйрәнү мәдәни багланышларның үсешенә хезмәт итә. Ч. Зариф тудырган образлар авторның шәхси дөнья сурәтен ача һәм аның иҗатының хронотопик киңлеген, төрлелеген концептуальләштерә.

**Эзләнү предметы** булып билингваль автор Чулпан Зарифның дөнья сурәте тудыру үзенчәлекләре, мәдәниятара багланышлар шартларында милли чынбарлыкны әдәби чагылдыру мөмкинлекләре, шагыйрәнең бердәм билингваль системасына хас үзлекләр тора.

**Эзләнү объекты –** Ч. Зариф лирикасы.

## Материаллар һәм методлар

Анализ өчен материал булып Чулпан Зарифның «Кояшка юл тота кәрваным» (2003) [1], «Апельсиновая осень» (2013) [2], «Lacivərd Yuxular» (2023) [3] җыентыклары, әсәрләре урын алган антологияләр [4], [5], [6], хрестоматия [7], шулай ук журналларда дөнья күргән татар, рус, төрек телләрендәге язмалар

[8], [9], [10], [11], [12], [13], [14], [15], [16], [17], [18], [19], [20], [21], [22], [23], [24], [25], [26], [27], [28] хезмәт итә. Эзләнү барышында максатка ярашлы төстә биографик, чагыштырма-тарихи, мәдәни-тарихи, герменевтик, структур-семантик методлар кулланылды.

## Фикер алышу

Бүгенге көндә гыйльмияттә билингв терминының тар һәм киң мәгънәдәге төшенчәләре мәгълүм. Киң мәгънәдә билингв дип, иң кимендә бер чит тел белүче санала. «Киң мәгънәдә икетеллелек термины әдәби тәрҗемәне дә үз эченә ала. Әдәби иҗатның бер төре буларак, әдәби тәрҗемә телләр һәм мәдәниятләрнең үзара багланышларына нигезләнә. Тәрҗемә – трансформация кичергән хәлдә яңа мәдәният контекстына кереп урнашып яшәүче әдәби факт ул», – дип белдерә Р.О. Туксаитова [29]. Тар мәгънәдә билингвизм төшенчәсе ике телне бер дәрәҗәдә камил белүне аңлата [30, б. 7].

Ч.Г. Гусейнов күпмәдәниятле илдә яшәүче икетелле язучыларның иҗатын биш төргә бүлә: 1) милли телдә иҗат итеп, рус теленә автор тәрҗемәсен тәкъдим итү; 2) рус телендә язып, милли телгә тәрҗемә итү; 3) рус һәм башка милли телләрдә иҗат итү, тәрҗемәгә мөрәҗәгать итмәү; 4) ике телнең фәкать берсенә – рус яки милли телгә вакытлыча яки тулаем күчү; 5) рус телендә язылган әсәрләрне милли әдәбият рәтенә кертеп исәпләү [31].

И.И. Валуйцева, Г.Т. Хухуни «язучының икетеллелеге» һәм «автор билингвизмы» кебек бер-берсенә охшаш мәгънәле төшенчәләрне аерырга киңәш итәләр: «Беренче очракта ике телне бер дәрәҗәдә белүче иҗатчы, икенчесендә туган теленнән башка тел(ләр)дә иҗат итә торган язучы күздә тотыла». «Белгечләр карашынча, автор билингвизмы, язучының ике телне дә камил белүе ул, ләкин һәр язучы ике телдә дә бердәй иҗат итми, гәрчә билингвизм элементлары бер генә телдә иҗат иткән очракта да шактый киң кулланыла ала[1] [32, б. 298-299]. Әдәбият галимнәре «язучының икетеллелеге» һәм «автор билингвизмы» булмаган, ике арада калган очраклар бар, диләр. Мисалга, «язучы ике телдә дә яза, әмма аерым бер мәдәниятка күбрәк хезмәт итә, бу очракта иҗатны ике телле дип әйтү дөреслеккә туры килеп бетми»[2] [32, б. 299].

Билингвизмның әдәби-гыйльми аспекты билингваль социумга мөнәсәбәтле һәм икетелле язучылар тарафыннан иҗат ителгән әсәрләрне анализлау, алардагы персонажлар сөйләмен бәяләүдән гыйбарәт [33], [34].

Чулпан Зариф 1977–1984 еллар аралыгында татар телендә, 1984–1988 елларда, нигездә, рус телендә, 1989–2007 елларда татар һәм рус телләрендә бердәй иҗат итә. 2008 елдан башлап татар, рус, төрек телләрендә яза. Аерым шигырьләре үзенең тәрҗемәсендә тәкъдим ителә.

Шагыйрә тумышы белән Казан артыннан. Мәгълүм булганча, Арча – милләткә Г. Курсави, Ш. Мәрҗани, Г. Тукай, Г. Бәширов, М.Мәһдиев һ.б. әдипләрне бүләк иткән данлыклы төбәк. Мәктәптә укыганда ук, Чулпан Зариф Габдулла Тукай туган көнне Казанда үткәрелә торган шигырь бәйрәмнәрендә катнаша. Аспирантурада уку елларында (1992–1994) бәйрәмдә тәүге тапкыр шагыйрә буларак чыгыш ясый.

Татарстан Республикасында 107 милләт вәкиле яшәп килә дип исәпләнә. Халыкның 90 процентын татарлар һәм руслар тәшкил итә, шул сәбәпле икетеллелек башлыча татар һәм рус телле булу дигәнне аңлата. Ч. Зариф рус мәктәбендә белем ала. Бу – күпмилләтле СССРда милли мәгарифне юк итү, бердәм урта мәктәп системасы формалашу дәвере. 1936 елгы Конституциядән аермалы буларак, 1977 елгы канунда милли телләрдә уку хокукы түгел, мөмкинлеге турында гына сүз алып барыла. Татар теле факультатив буларак укытыла башлый. Чулпан Зарифның яшьтән үк ике телдә язуы шуңа да очраклы түгел. Гаиләдә татар телендә аралашсалар да, район үзәгенә күчеп киткәннән соң, дүрт баланың өчесе рус мәктәбендә белем ала. Туган телгә мәхәббәтне татар теле укытучылары тәрбияли. «Гаиләбез белән Арчага күченгәндә, миңа 5 яшь иде. Мин рус телле 1 санлы Арча урта мәктәбендә укый башладым. Туган телемә мәхәббәт уянуда татар теле укытучылары хәлиткеч роль уйнадылар. Гаиләдә дә без фәкать татар телендә аралаша торган идек. Татар һәм рус телләрендә бердәй иркен аралашканлыктан, мин ике телдә дә җиңел иҗат итә ала идем», – дип искә ала шагыйрә бер әңгәмәсендә [35].

[1] В. Набоков иҗаты – бу күренешнең ачык мисалы.

[2] А.С. Пушкин яки Ф. Тютчевның француз телендәге шигырьләрен кара.

Чулпан Зарифның шигъри таланты ачылуга «Коммунизмга» дип исемләнгән район газетасы (1992 елдан башлап газетаның исеме «Арча хәбәрләре») каршында эшләп килгән «Тукай якташы» әдәби-музыкаль оешмасының йогынтысы көчле була. Әлеге оешмага йөргән укучы кыз Казанда телевизион конкурсларда катнаша. 1977 елда аның беренче шигырьләре татар телендә, 1980 елларда рус телендә басыла [35]. Әдәби-музыкаль оешманы газетаның җаваплы сәркатибе язучы Радик Фәизов (1931–2011) җитәкли. Оешмага төрле профессия вәкилләре, төрле яшьтәге кешеләр йөри. Чулпан Зарифның тәүге шигырьләре 1995 елда «Казан утлары» журналында «Остаханә» дип исемләнгән бүлектә шул оешмага йөрүчеләрнеке белән бергә дөнья күрә [8]. Тәүге иҗат җимешләренә шәрык шигърияттен тирән белгән шагыйрь Рәдиф Гаташның бәя бирүе дә очраклы түгел: «Чулпан Зариф шигырьләре сөенеч, ышаныч хисләре уята: мин аларны һичшиксез, табигать биргән сәләт һәм моңлы күңел кичерешләре, рух эзләнүләре җимеше, безнең шигырьгә тагы бер кызыклы каләм иясе, үзенчәлекле шагыйрә килүдән хәбәр дип кабул иттем» [8, б. 89].

1987 елда Ч.Ә. Зарипова-Четин Казан дәүләт университетының филология факультетына милли мәктәптә рус телен укыту бүлегенә укырга керә. 1988 елда Казан дәүләт педагогика институтының (1995 елдан КДПУ) тарих-филология факультетына күчә. Биредә укыганда, Ч.Ә. Зарипова-Четин «Компаративистика» дип исемләнгән махсус курска языла, чагыштырма әдәбият белеменең нигезләрен үзләштерә, әдәби янәшәлекләр (стиль, сюжетлар һ.б.) һәм төрле әдәбиятлар арасында уртаклыкларны өйрәнә. Фәнни җитәкчесе А.М. Саяпова тәкъдиме белән НИРС кысаларында М.Ю. Лермонтов һәм С. Рәмиев шигъриятләрен чагыштырма-тарихи яссылыкта өйрәнүгә алына. Ч. Зарипова-Четин үзе: «Студент чактагы әлеге эш язмышымда хәлиткеч роль уйнады. Реферат «Шәрык-гареб эстетикасы контекстында Сәгыйть Рәмиев иҗатында демонизм проблемасы» («Проблема демонизма в творчестве М. Лермонтова и С. Рамиева») дип исемләнгән диплом эше дәрәҗәсенә үсте, укуны тәмамлаганнан соң җитди фәнни эзләнү юлына алып чыкты», – дип искә ала [36, б. 298]. Диплом эшенең рецензенты итеп атаклы әдәбият галиме Р.К. Ганиева билгеләнә. Чулпан Зарифта автор билингвизмы үсешенең беренче алшартларының кайберләре шулар була.

Чулпан Зарифның башлангыч чор иҗатындагы күңел лирикасына Р. Гаташ [8, б. 89], Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләм, Г. Гыйльманов [1, б. 116], Эльхан Зал Караханлы [2, б. 3-4]), әдәбият белгече Ә. Нәҗипова [37, б. 134], галимә Л. Минһаҗева [38, б. 142] бәя бирәләр.

Башлангыч чор шигырьләрендәге эпиграфлар әдибәнең зәвыгын тоемлау мөмкинлеге бирә. Чулпан Зариф үзешчән шагыйрьләр иҗатына игътибарлы. Ул Лаймдот Ливена исемле латыш шагыйрәсе (тәхәллүсе Лайма Ливена, 1943), фин телендә язучы Карелия шагыйре Армас Иосифович Мишин (тәхәллүсе Олег Мишин, 1935–2018), рус шагыйрәсе Марина Цветаева (1892–1941) иҗатларына мөрәҗәгать итә. СССРда яшәүче халыклар әдәбиятына гаять игътибарлы Чулпан Зариф «Мин үзем» (1987) шигырендә үзе белән «Татарстаннан килгән татар кызы» дип таныштыра [2, б. 44]. Шагыйрә татар халкы, үз милләте белән горурлыгын бөтен иҗаты аша үткәрә.

1992 елда Ч. Зарипова-Четин туган университетына кайтып, татар әдәбияты кафедрасына аспирантурага керә. 1995 елда А.М. Саяпова җитәкчелегендә «Шәрык-гареб эстетикасы контекстында Сәгыйть Рәмиев иҗатында демонизм проблемасы» [39] дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. С. Рәмиев иҗатын өйрәнү барышында Чулпан Зарипова-Четин алдында татар әдәбиятының тирән төпкелләре ачыла. Әдәбият белгече фәнни эзләнүләрендә шәрык белән гаребне бербөтен итеп тасвирлауга һәм милли шигъриятне дөнья әдәбияты кысаларында өйрәнүнең әһәмиятен дәлилләүгә ирешә. Диссертация кысаларында С. Рәмиев иҗаты М. Ю. Лермонтов, К. Бальмонт, И. Нәсими шигърияте белән янәшәлектә, Ф. Ницше һәм Х. Җәбраннарның фәлсәфи карашлары яссылыгында өйрәнелә [36, б. 248]. Рәдиф Гаташ беренчеләрдән булып, яшь белгечнең гыйльми карашлары үсешенә әдәби иҗатының йогынтысын тоемлап ала: «Әйе, Чулпан дөнья, рус шигъриятен, әмма барыннан да бигрәк шәрык әдәбиятын, бөек гарәп-фарсы, төрки шагыйрьләрен өйрәнгән һәм бу аның шигырьләрендә дә чагыла. Шигъри сурәтләрдә, фикер бирелешендә, тел-стиль чараларында, сүз-лексиконда моны тою авыр түгел» [8, б. 89].

Гыйльми хезмәтне яклаганнан соң Ч. Зарипова-Четин татар әдәбияты кафедрасына эшкә алына. Бу исә белгечкә билингвизмны үстерү юлында өстәмә этәргеч булып тора. Үз сүзләренә караганда, рус-татар бүлеген тәмамлаган кызга саф татар бүлегенә килеп эшли башлау җиңелләрдән булмый, икенче яктан, белгечкә милли мәдәният белән якыннанрак танышу, урта мәктәптә үк алырга тиешле булган белемнәрен системалаштыру мөмкинлеге туа. [36, б. 249]. 1995–1999 елларда Ч. Зариф КДПУның татар филологиясе факультетында татар әдәбиятыннан, татар халык авыз иҗатыннан, XX йөз башы татар әдәбиятыннан һәм шәрык халыклары әдәбиятларыннан лекцияләр укый. Шул ук вакытта рус филологиясе факультетында рус телендә татар әдәбияты курсын алып бара. Мөгаллимә буларак Чулпан Зариф «Илһам» иҗат берләшмәсе белән җитәкчелек итә. Кызганычка каршы, берләшмәгә йөрүче яшьләрнең шигъри бәйләме, финанс мөмкинлекләре булмау сәбәпле, китап буларак басылмый кала. «Илһам» берләшмәсенә йөргән студентлар арасында киләчәкләрен иҗат эше белән бәйләгәннәре дә бар. Мисалга, Гөлүсә Закирова шундыйлардан. Мөгаллимлек иткән чорында Чулпан Зариф радио һәм телевидениедә әдәби тапшыруларда, «Шәрык клубы» эшчәнлегендә дә актив катнаша.

1990 елларда шагыйрә рус һәм татар телләрендә иҗат итә, «Мәгърифәт», «Мәдәни җомга», «Шәһри Казан», «Ватаным Татарстан» газеталарында, «Казан утлары», «Идел», «Сөембикә» журналларында татар телендә басыла. Шагыйрәнең күңел лирикасы аны милли шигърияттә шәрык мотивларын тергезгән иҗатчы буларак таныта [1, б. 116], [37, б. 134]. «Туксанынчы еллар шигъриятенең иң зур казанышы милли тематика иде. Ә минем керткән өлеш, мөгаен, көнчыгыш мотивлары булгандыр. Чөнки мәктәп елларыннан бирле көнчыгышка, көнчыгыш шигъриятенә, Төркиягә гашыйк идем…» – дип белдерә Чулпан Зариф бер әңгәмәсендә [40].

«О низкое небо Востока!» (“И Шәрыкның түбән күк гөмбәзе”) [2, б. 26], «Почему-то хочется» (“Никтер телим”) [2, б. 27], «Монолог придворного поэта» (“Сарай шагыйре монологы”) [2, б. 28], «Я вся была зло» (“Мин тоташ явызлык идем”) [2, 127 б.] кебек шигырьләре әле Төркиягә барганчы, Истанбулны күрмәгән килеш язылган булса, 1997–1998 елларда Истанбул һәм Аланиягә сәяхәт кылганнан соң Чулпан Зариф шигъриятенә төрек темасы ныклап кереп урнаша («Истанбулда җәйнең соңгы мизгелләре» циклы [1, б. 86–113], «Ак диңгезнең күз яшедәй тозлы суы» цикллары). Рус һәм татар телләрендә язылган шигырьләрендә әдибә еш кына Төркиянең үз язмышындагы ролен ассызыклый. Чулпан Зарифның дөнья сурәтендә үткән-бүгенге бөтенлеге, хәтер образы өстенлекле:

Мәрмәр диңгез буе – гөлләр...

Сезгә саксыз кагылдыммы?

Учымда – алтын тузан...

Тузаннан яңарып, янә синә килгәнче, Истанбул,

Күпме гасырлар узган!.. [1, б. 113]

Төркиягә күченеп киткәннән соң да бу мотив алгы планда кала:

Стамбул! Тебя люблю давно и безвозвратно...

На сердце – как печать... На родину обратно,

Не знаю, ляжет путь. Или судьба – быть здесь...

Стамбул!

Ты на моём челе с рожденья есть... [2, б. 145]

(Истанбул! Мин гашыйкмын сиңа...

Күптәннән, гомерлеккә!

Йөрәгемдә – мөһер кебек син!

Кире туган җиргә

Юлым бармы – белмим.

Мин туганнан бирле синең мәҗнүн) (тәрҗемә – А.Г.).

Әңгәмәләрендә Чулпан Зариф төрек телен Казанда өйрәнүен, мәктәп елларыннан ук төрек язучыларының әсәрләрен яратып укуын, үсмер чагыннан бирле Төркиягә сәяхәт итәргә хыялы барлыгын белдерә. Әтисе сүзләренә караганда, аның әбисе дә Төркиядә булып кайтырга теләгән [40]. «Мәктәп елларыннан ук язмышымның Төркия белән бәйле буласын сизеп яшәдем... Мин теләкләрнең ихлас һәм көчле булган очракта чынга ашуына ышанам!», – ди Чулпан Зариф[41, б. 54].

Истанбул турындагы хыяллары урта мәктәптә укыганда танышкан әдәби әсәрләрдән бөреләнгән булса кирәк, Чулпан Зариф үзенең шигырьләрендә төрек героиняларына мөкиббән икәнлеген сиздерә:

Мечети шахзаде, султанов и их жён.

Сей град интригами и сказкой окружён...

Не знаю, кем была – наложницей, царицей...

Стамбул!

Мне до сих пор та жизнь, что в прошлом, снится... [2, б. 145]

(Шаһзадә, солтаннар һәм хатыннары мәчетләре.

Ошбу шәһәр серләргә һәм экияткә төрелгән..

Белмим, кем идем – кәнизәкме, ханбикәме...

Истанбул!

Төшләремә һаман үткәндәге тормыш керә...) (тәрҗемә – *А.Г.)*

«Монолог придворного поэта» («Сарай шагыйре монологы») шигырендә аң төпкелендәге хәтер темасы калкытыла, шагыйрә үзен сарай шагыйре образы белән янәшә куя [2, б. 28]. «К Джебрану» («Җәбранга») шигырендә дә шул ук мотив алга чыга [2, б. 130].

Чулпан Зарифны Истанбулның архитектурасы әсир итә, аеруча Айя-София таң калдыра:

Почему-то хочется
Ступать неторопливыми шагами
По пустым улицам старого Стамбула...
И, запрокинув голову,
Смотреть на Айя-Софию... [2, б. 25].
(Нигәдер атлыйсы килә
Әкрен адымнар белән
Истанбулның буш урамнары буйлап...
Һәм, башны күтәреп,
Айя-Софиягә карыйсы...) (тәрҗемә – *А.Г.*)

Ч. Зариф шигъриятендә Истанбул базары – шәрыкның җанын символлаштыра торган образ ул:

И вдруг оказаться
В гуще Стамбульского базара,
Где, вобрав под себя ноги,
Дремлет старый турок
в сбившейся набок чалме...
И, улучив момент показать смуглую щёчку,
Нежные пальчики приподнимают чадру чёрную.
Где хитрые греки торгуют шелками зелёными –
Цвета Османов.
Где слышится дерзкий смех женщины –
В прошлом гяурки... [2, б. 27].
(Һәм кинәт кенә калырга
Истанбул базары уртасында,
Кайда, аякларын бөкләп,
карт төрек йокымсырый,
кырыйга авышкан чалмалы...
Һәм мизгел тотып, кара кучкыл йөзне күрсәтергә,
Кара бөркәнчекне күтәрә назлы бармаклар.
Кайда хәйләкәр греклар яшел ефәк –
Госманлы төсе белән сату итә.
Кайда хатын-кызның әрсез көлүе ишетелә –
Элеккеге гәүерләр...) (тәрҗемә – А.Г.).

Шагыйрә әлеге шәһәрне Роксолана (Хөррәм солтан) турындагы легенда яктылыгында кабул итә. Бу образ белән ул П. Загребельныйның «Роксолана» [43] исемле тарихи романы аша таныша:

И хочется вновь
Ощутить жаркий полдень Стамбула
И запах волос Роксаланы
Цвета червонного золота... [2, б. 27].
(Һәм кабат тоясы килә
Истанбулның кызу өйләсен
Һәм Роксолананың
Кызыл алтын чәчләре исен...)
(тәрҗемә – А.Г.).

1997 елда Чулпан Зарифны Истанбулга килергә дәртләндергән легенда да шушы.

«Мечети Стамбула, что круче и выше...» («Бөекләрдән бөек, биекләрдән биек Истанбул мәчетләре...») шигырендә Госманлы империясе рухы тоемлана [2, б. 146]. Шагыйрә шәһәрнең җанлы, илаһи сурәтен тергезә [2, б. 146], [12, б. 37]. «Я вся была зло» («Мин тоташ явызлык идем») (1994) шигырендә Истанбулга якын Садабад шәһәре искә төшерелә, XVII–XVIII йөзләрдә төрек шагыйрьләре яз башында – лаләләр чәчәк аткан ямьле вакытта биредә җыела торган булалар [2, б. 127].

Шигырьләрнең мәгънәви колачы да аларның кайсы телдә язылуына бәйле. «Почему-то хочется» («Никтер телим») [2, б. 27] һәм «Мечети Стамбула, что круче и выше...» («Бөекләрдән бөек, биекләрдән биек Истанбул мәчетләре...») [2, б. 146] шигырьләрендә лирик герой башлангычта чиркәү булган Айя-София мәчетенә, ә татар телендә язылган шигырьләрдә Баязид, Сөләйман, Шахзадә мәчетләренә, төрек солтаннары резиденциясе Топкап сараена, Босфор өстендәге күпергә, Коръәнгә, шулай ук төрек-мөселман көнитешенең аерылгысыз атрибутлары – намаз, азан, әсирә, суфый һ.б. образларга мөрәҗәгать итә [2, б. 106], [2, б. 110], [2, б. 112].

Чулпан Зариф иҗатында Мисыр патшабикәсе Клеопатра темасы да калку гәүдәләнеш ала («Ак диңгезнең күз яшедәй тозлы суы» циклы [1, б. 87] һәм «Клеопатра! Жадный взгляд» («Клеопатра! Комсыз караш» шигыре [2, б. 135]). Эгей диңгезе ярында урнашкан Мугла шәһәренә күченгәннән соң,

аның шигъриятендә борынгы юнан шагыйре Гомер, аның «Илиада»сындагы Парис һәм Елена, [2, б. 136], [2, б. 151] яһүд патшасы Соломон (Сөләйман) [2, б. 137] образлары пәйда була.

Туган җирен сагыну дәрте белән шагыйрә татар телендә дә күп яза («Хөрмәләр өлгерә, бананнар» [1, б. 95], «Бөтен дөньясында бер бушлык» [1, б. 96] , «Җилле көндә диңгез буен иңлим» [1, б. 97], «Зәйтүн күзле улым минем» [13], «Ап-ак чәчәктә, күр, өрек агачы» [1, б. 103], «Эгей хәрабәләрендә» [6, б. 316], «Таулар чалма киеп, тәсбих тарта» [6, б. 317] h.б.)., рус телендә дә иҗат итә («Здесь нет зимы, здесь апельсиновая осень» («Монда кышлар юк, монда әфлисун көзләр») [2, б. 133], «В развалинах Трои» («Троя хәрабәләрендә») [2, б. 136], «Колыбельная сыну» («Улыма бишек җыры») [2, б. 138], «Истанбул!» [2, б. 145], «Синь морей и зелень кипарисов» («Зәңгәрсу диңгезләр һәм яшел кипарислар») [2, б. 151] h.б.).

2007 елдан башлап, Чулпан Зариф төрек телендә иҗат итә башлый («Bir Başka Diyarda» («Башка илдә»), «Sensizlikten» («Синсезлектән»), «Gökyüzünün mavisi zeytinlerin yeşili» («Күкнең зәңгәрлеге – зәйтүннәрнең яшеле») [28], «Tek cihanın mı siması sarı renge boyandı?» («Бары тик җиһанның йөзе сары төскә буялганмы?») [19], «Bir Dize Şiir Kaldı» («Шигырьнең бер юлы калды») [24], «Denizde» («Диңгездә»[25] h.б.).

Шәрык мотивлары аның иҗатының эчтәлегендә генә түгел, формасында да чагылыш таба. Шагыйрәнең бу үзенчәлегенә Р. Гаташ игътибар итә: «Шәкли яктан да матур аның шигырьләре – монда да Чулпанның җитди мәктәп үткәнен тоясың». [8, б. 89]. 1980–1990 елларда Чулпан Зариф каләмен газәл жанрында сынап карый («Газәл» [1, б. 42], «Ты храм огня...» («Син ут гыйбадәтханәсе...» [2, б. 78]); робагый жанрына мөрәҗәгать итә («Йолдыз идем» [1, б. 6]; «Усал, ди, без» [1, 45 б.], «Я положила сердце на ладонь...» («Учларыма куям йөрәгемне») [2, б. 42].

Билингв-язучы Чулпан Зариф шигырьләргә төрле телләрдәге сүзләрне файдаланып, күпмәгънәлелеккә ирешә. Мисал өчен:

Цвела в столице липа… И мёдом пахла ночь.

Твои глаза так близко, так близко, что невмочь!

И опрокинул небо Всевышний в наш бокал…

И с трепетом шепнули твои мне губы: «Kal...» [2, б. 150].

(*Kal* (тур.) – останься);

İki şam yanıyor, iki mum…

Hem senin hem benim umudum.

O iki olan şam. Bizse tam!

“Yaratam, bik katı yaratam…”

(Tatar Türkçesinde “seviyorum, çok seviyorum anlamında) [22, б. 100].

(Юкә чәчкә ата... Бал исе ягыла төнгә...

Күзләрең шулкадәр якын, хәтта сабырлыгымны җуйдым!

Аллаh безнең касәгә күкләрне аударды.

Иреннәрең миңа «Кал...» – диде) (тәрҗемә – А.Г.)

Текстларның билингваль сөйләшүе гади һәм катлаулы бәйләнешләр тудыра. Шигырьләренә Чулпан Зариф этнопоэтизмнар да кертә. Мисал өчен, лирик геройның хисләренең чуалуын үтемлерәк бирү өчен автор «Ак калфак» (1923) музыкаль драмасыннан «Хәмдия» көен (Татар халык көе, М. Фәйзи сүзләре) файдалана:

«Хәмдиягә сүз кушмагыз,

Зиhене таралган чагы.» [1, б. 49].

Бу алым ярдәмендә шагыйрә лирик геройның хисләрен тирәнрәк бирүгә ирешә.

«Хәмдиянең акылдан язуы» шигырендә дә музыкаль драмадагы персонаж – бу җырны уйлап тапкан Бакый исемле көтүче белән диалог тоемлана [1, б. 50].

«Кояшка үрмәләгән сары көнбагыш кебек» шигырендә Чулпан Зариф геройның чарасызлык халәтен ачыграк чагылдыру өчен Сак-Сок бәетенә мөрәҗәгать итә:

Елгалар да бер агып кушылырлар диңгезгә!

Сак-Сок булдык... Кавышу дөньялыкта юк безгә.

Дәртебезгә юк дәрман... [6, б. 320].

Кайбер шигырьләрендә диалог катлаулы – коннотатив дәрәҗәдә: оригинал тексттагы образлар яңа мәдәни мохиткә беркадәр үзгәртелеп, шул мәдәнияткә яраклаштырып кертелә. «Перед венцом» («Туй алдыннан») шигыре Ф.С. Журавлевның шул исемдәге картинасына аваздаш [2, б. 33]. Рәссам 1874 елгы картинада ата кешенең кызына туй алдыннан хәер-фатиха бирүен гәүдәләндерә, исәп-хисап буенча кияүгә бирелә торган кызның шәхси фаҗигасен, хыяллары челпәрәмә килүен тасвирлый. Туйдагы татлы тәгамне хәтерләткән нәзберек кыз бала – гаиләләр арасында килешү төзү чималы. Ф.С. Журавлев кызның эчке кичерешләрен тирән бирүгә

ирешә. Мәгълүм булганча, замандашлары картинаны яратып каршы ала, рәссам әлеге иҗат җимешенә ике тапкыр әйләнеп кайта. Картинаның сюжеты әдәби. Чулпан Зарифның шул исемдәге шигырендә дә рус поэзиясе традицияләренә таяну күзәтелә. Безнең карашка, биредә М. Цветаева лирикасы мотивлары да тоемлана.

«Стоит один в холодном храме» («Салкын гыйбадәтханәдә берьялгызы басып тора») [2, б. 26] шигырендә чиркәүдә Гайсә пәйгамбәр портреты гәүдәләндерелә. Биредә дә шагыйрә рус поэзиясенең Көмеш дәвере традицияләренә таяна. Шул ук вакытта Г. Ибраһимовның «Көтүчеләр» әсәре белән дә аваздашлык сизелә [44].

Чулпан Зарифның ике тел һәм мәдәнияткә даими рәвештә мөрәҗәгать итүе әдибәнең образлы фикерләвенең ике телдә формалашуы өчен алшартлар булдыра. Ул шигъри форма, төрле мәдәниятләрнең символларын, интонацион мөмкинлекләрен үзләштерә, татар, төрек һәм рус дөнья сурәтен тоташтыручы нокталарны өйрәнә, әсәрләренә урнаштыра (мисал өчен, «Не христианка я…» («Христиан кызы түгел мин…») [2, б. 123], «Пусть каждую минуту я другая» («Мизгел саен үзгә булсам да») [2, б. 119], «Зәйтүн күзле улым минем» [6, б. 312]; «Ап-ак чәчәктә, күр, өрек агачы!..» [1, б. 103], «Чарасыз бадәмнәр бәс кебек чәчәктә» [6, б. 313]; «Сәрбиләргә тагып тамчы-алкасын...» [6, б. 321]; «Sonbaharın solgun soğuk nefesi»(«Көзнең аксыл салкын сулышы»[22, б. 100], «Sazının teli olurdum, ellerin dokunsun diye» («Сазыңның кылы булыр идем, кулларың кагылсын дип») [22, б. 100].

| | |
|---|---|
| Senden ayrı düşmek kadar yok zülüm. Yakar sanki acı Arap kahvesi…[22, б. 100] | Синнән аерылу газабыннан көчлерәк газап юктыр. Ягар, әйтерсең ачы Гарәп каһвәсе... |

| | |
|---|---|
| Tarlanda ekin olurdum, gün gelir biçersin diye Haremde kölen olurdum, gün gelir seçersin diye. [22, б. 100] | Кырыңда иген булыр идем, көн килер игәрсең дип. Сарайда колың булыр идем, көн килер сайларсың дип. |

Билингваль менталь диалог нәтиҗәсендә шагыйрә үзен ике – татар һәм рус, татар һәм төрек мәдәниятләренә нисбәтле итеп тоя һәм үстерә. Мондый «икеләтелгән» аң Чулпан Зарифның ике төрле дөнья сурәтен биргән шигырьләрендә калку чагылыш таба (мисал өчен, «Гөлчәчәкне кулыннан төшергән Пир Солтан Абдалга» [1, 40 б.], «К Бальмонту» («Бальмонтка») [2, 129 б.]). Шул рәвешле, билингв шагыйрә ике мәдәнияттәге текстларның мәгънә мөмкинлекләрен киңәйтүгә ирешә. Моңа чит ил тәнкыйтьчеләре, аерым алганда, Э. Зәл Караханлы [2, 4-5 б.], Д. Чкония [16] игътибар итәләр. Мисал өчен, «К Бальмонту» («Бальмонтка») шигырендә Чулпан Зариф, кешеләр арасында үзеңне ялгыз хис итү халәте турында язганда, шагыйрьнең «Сквозь строй» («Строй аша») дип аталган мәгълүм шигыре белән диалогка керә. «Янам» дигән тезмә – башка мәдәнияттән алынма («Мин янам, мин яндым һәм сүнмәдем») [2, 129 б.]. Чыганакны аңлаган укучы автор позициянә шундук төшенә. «Думая о Джебране» («Җәбран турында уйланганда» [2, б. 130], «И будет также течь Арагва» («Арагва шулай агар да агар») [16] шигырьләре дә шундыйлардан.

Шагыйрә еш кына авторның үзен һәм мәгълүм геройларның исемнәрен файдалана. «Мәҗнүнме син ялгыз чүлдә ятып калган» (1994) [1, б. 11] һәм «Ләйләм дип янган Мәҗнүн» (2003) [1, б. 100] шигырьләрендә шәрык әдәбиятларында еш кулланыла торган дастан геройлары тергезелә. Ләйлә һәм Мәҗнүн образлары рус телендә [2, б. 127] һәм төрек телендә язылган шигырьләрдә [23, б. 98] очрый.

Әгәр Чулпан Зариф рус телендәге шигырьләрендә рус мәкальләрен кулланса, татар һәм төрек телләрендәге шигырьләрендә татар һәм төрек мәкальләренә һәм әйтемнәренә мөрәҗәгать итә: «Говоришь, ведут дороги / Только в Рим?» [2, б. 125]; «И будет скорбеть о Незабвенном / Черная Роза Тифлиса, / Напоминая, что горе от ума...» [16]; «Кеше китә – җыры кала, дигәннәр... / Әни, минем җырымны да җырлачы!..» [1, 103 б.]; «Ateşten gömlek giymişim nasıl olurum esen?» (Надела рубашку из огня, как же мне быть живой? / Рубашка из огня, тождественно «сгораю» [23, 98 б.].

Әдәбият галиме М.В. Казакова фикеренчә, «икетелле әдәби текст мәдәниятара бәйләнешләр нәтиҗәсендә барлыкка килә; кешеләр, милләтләр арасындагы бәйләнешләр дәрәҗәсендәге бу күренеш бүгенге күпмәдәниятле заманда әдәбиятта аеруча әһәмиятле. Әдәбият күптавышлылык үзлегенә ия. Шуңа күрә аңның күпмәдәниятле асылы һәм әдәби текстта әлеге диалогның урыны

проблемасы әдәбият гыйлемендә эзләнү өчен нигез була ала» [45, б. 25].

2002–2012 елларда Чулпан Зариф Мугла шәһәре университетындагы әдәбият факультетының «Заманча төрки телләр һәм әдәбиятлар» кафедрасында эшли. Галимәгә татар фольклоры, татар теле, әдәбияты, рус теле дәресләрен укытуны йөкләләр. Чулпан Зариф төрле дәрәҗәдәге конференцияләрдә өч телдә язылган фәнни мәкаләләре аша татар әдәбиятын таныта. Аның монографияләре шулай ук чит мохиттә татар фольклорын, милли әдәбиятыбызны пропагандалауга хезмәт итә. Алар өч телдә нәшер ителә [46], [47], [48], [49].

Чулпан Зариф талантлы тәрҗемәче буларак та танылa. Аның фидакарь хезмәте нәтиҗәсендә төрек укучысы Гаяз Исхакый, Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Сәгыйть Рәмиев, Дәрдемәнд, Мәҗит Гафури, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гаташ, Мөхәммәт Мирза, Роберт Миңнуллин, Ркаил Зәйдулла, Зиннур Мансур һәм башка татар әдипләренең иҗатлары белән таныша [49], [50], [51], [52], [53]. Ул шулай ук төрек шагыйре Юныс Әмрә һәм азәрбайҗан шагыйрьләренең шигырьләрен рус теленә тәрҗемә итә [54], [55]. Шулай ук хәдисләрне төрек теленнән русчага тәрҗемә итү проектында катнаша [56].

2011 елда Ч. Зарипова-Четин Карс шәһәренә күченә. 2012–2018 елларда Кавказ университетында славян телләре һәм әдәбиятлары кафедрасын җитәкли. Славян телләре һәм әдәбиятлары бүлегендә эшләү дәверендә рус теле һәм әдәбиятыннан курс алып бара, шулай ук Әлифба бәйрәме, Май җыю, Яңа ел кебек рус бәйрәмнәрен оештыра. Бер вакытлар Россия империясенең провинциясе булган Карс шәһәренең рус әдәбияты һәм сәнгатенә чагылышы белән бәйле мәкаләләр яза. 2018-2019 елларда «Заманча төрки телләр һәм әдәбиятлар» бүлеген җитәкли. Әлеге бүлектә ул татар әдәбияты, төрки фольклор һәм әдәбиятларны чагыштырма өйрәнү, әдәбият социологиясе, поэтик текстка анализ, рус теле һәм әдәбияты предметларын укыта. Фәнни эшчәнлеген ватандашыбыз өч телдә алып бара.

## Нәтиҗәләр

Әлеге мәкалә бу катлаулы теманы өйрәнүдә беренче омтылыш булып тора. Без Чулпан Зариф-Четинда автор билингвизмы калыплашуына уңай йогынты ясаган факторларны ачыкладык:

- шәхеснең ике телле шартларда формалашуы,
- КДПУның рус-татар бүлегендә белем алуы,
- компаративистика юнәлешендә фәнни эшчәнлек алып баруы,
- мәктәп елларыннан ук шәрык дөньясы, аерым алганда, Төркия белән кызыксынуы,
- чит милләт мохитендә педагогик эшчәнлек,
- укучылар географиясен киңәйтү өчен мөһаҗирлектә тел алыштыруга ихтыяҗ барлыкка килү,
- чит илдә милли үзаңның көчәюе һәм шуның нәтиҗәсе буларак, иҗат, тәрҗемәләр, монографияләр һәм фәнни-популяр китаплар аша туган мәдәниятен чит илләрдә актив рәвештә таныту.

## Йомгак

Шагыйрәнең лирикасы аның шәхси тормышы белән тыгыз бәйләнгән. Чулпан Зариф татар, рус һәм төрек телләрендәге шигырьләрендә шәхси хис-кичерешләрен чагылдырырга омтыла. Лирикасында мәгъшука лирик «мин» образында ул еш кына үзе күренеп китә. Лирик герой үзен татар һәм төрки мәдәниятләренең бер өлеше итеп таный. Милли үзбилгеләнеш аңа олы һәм кече ватанын тоярга мөмкинлек бирә. Текстка чит кодларның үтеп керүе лирикасының контекстуаль планын да киңәйтә, эстетик мәгънәсен арттыра, укучыны мәдәниятләр арасында арадашчы итә. Билингв язучы чит мохиттә бер тел ярдәмендә еш кына монолингваль тел системасына буйсынмаган яңа эчтәлектәге текст тудыруга ирешә.

**Әдәбият**


1. *Зариф Ч.* Кояшка юл тота кәрваным. Шигырьләр. Казан: “Матбугат йорты” нәшр., 2003. 120 б.
2. *Зариф Ч.* Апельсиновая осень: стихи. Казань: Татар. кн. изд-во, 2013. 160 с.
3. *Zərif Ç.* Lacivərd Yuxular Bakı: AybKitab, 2023. 102 səh.
4. *Зариф Ч.* Стихотворения. // Современная татарская поэзия. Казань: Татар. кн.изд-во, 2008. 184–188 с.
5. *Зариф-Четин Ч.* Стихотворения. // Из века в век. Поэзия народов кириллической азбуки. Татарская поэзия. М.: ИКАР, 2024. С. 562–569.

6. *Зариф Ч.* Төркия. // Кыйтгалардан килә татар сүзе. Казан: Милләт, 2022. 302–323 б.

7. *Зариф Ч.* Шигырьләр. // Без бит – Арча яклары. Арча төбәге әдипләре иҗаты. 9–11нче сыйныф укучылары өчен хрестоматия. Казан: «МӘГАРИФ-ВАКЫТ» нәшрияты, 2016. 255–257 б.

8. *Зариф Ч.* Зәңгәр кыялар. // Казан утлары. 1995. 89–94 б.

9. *Зариф Ч.* Таулар томанда анда. // Идел. 1995. № 4. 2-3 б.

10. *Зариф Ч.* Шигырьләр. // Сөембикә. 1996. № 4. 30–31 б.

11. *Зариф Ч.* Акдиңгезнең күз яшедәй тозлы суы. // Идел. 1999. № 6. 2–3 б.

12. *Зариф Ч.* Төркиядән – илгә, Иделгә. Шигырьләр. // Казан утлары. 2007. № 3. 37–40 б.

13. *Зариф Ч.* Зәйтүн күзле улым. // Сөембикә. № 6. 2008. 32–33 б.

14. *Зариф Ч.* Сагынам сине һаман. // Сөембикә. № 9. 2013. 38–39 б.

15. *Зариф Ч.* Погасших звёзд серебряная пыль. // Литературная газета, 22 ноября, 2017. https://lgz.ru/article/-46-6621-22-11-2017/pogasshikh-zvyezd-serebryanaya-pyl/

16. *Зариф Ч.* Стихи // Эмигрантская лира, №2, 2021. https://emlira.com/2-34-2021/chulpan-zarif/stikhi

17. *Зариф Ч.* Әни, минем җырымны да җырлачы... // Мәдәни җомга. 2024. №2. 19 гыйнвар. 7 б.

18. *Зариф Ч.* Синең күк янам мин, әй кояш // Казан Утлары. 2024. № 7. 82–86 б.

19. *Zaripova-Çetin Ç.* Bir Satır Şiir Kaldı // Kümbet, 2009. №14. S. 87.

20. *Zaripova-Çetin Ç.* Yagmurlı Geçede // Kültür çağlayanı. 2010. №3. S. 35.

21. *Zaripova-Çetin Ç.* Bir Yıldızdan // Kültür çağlayanı. 2010. №1. S. 19.

22. *Zarif Ç.* Şiirler. // Çinar. 2010. №2, S. 98–100.

23. *Zaripova Ç.* Ateşten Gömlek. Türkçe ve İngilizce. // İstanbul'un Şiiri Dünyanın Şairi. İstanbul: Sultanbeyli Belediyesi. 2013. S. 97–99.

*24. Zaripova-Çetin Ç.* Denizde // Hece Taşları. 2023. 9. yıl 105. sayı / 03 S.11.

25. *Zaripova-Çetin Ç.* Bir Dize Şiir Kaldı // Hece Taşları. 2023. 9. yıl 101. sayı / 03 S.22.

26. *Zarif Ç.* Yağmur Yağar // Kardeş kalemler. 2025. № 224. S. 48–49.

27. *Zarif Ç.* Nice Nehir Kayıp Denizlerde // Kardeş kalemler. 2025. № 223. S.11–14.

28. *Zarif Ç.* Özledim // Kardeş kalemler. 2025. № 220. S. 8–11.

29. *Туксаитова Р.О.* Художественный билингвизм: к определению понятия // Известия Уральского государственного университета. Серия 2: Гуманитарные науки. 2005. №39. С. 198–206.

30. Многоязычие и литературное творчество: [Сб. статей] / АН СССР, Ин-т рус. лит. (Пушкин. дом); [Отв. ред. М. П. Алексеев]. Ленинград: Наука: Ленингр. отд-ние, 1981. 339 с.

31. *Гусейнов Ч. Г.* Проблемы двуязычного художественного творчества в советской литературе // Единство, рожденное в борьбе и труде: Новая историческая общность людей – советский народ и литература социалистического реализма: материалы Всесоюз. конф. М., 1972. С. 314–315.

32. *Валуйцева И.И., Хухуни Г.Т.* Литературный билингвизм: за и против // Полилингвальность и транскультурные практики. 2015. №5. С. 298 – 303.

33. *Михайловская Н.Г.* О проблемах художественного литературного двуязычия // Вопросы языкознания. 1979. №2. С. 61–72.

34. *Азарова Н.М.* Поэтический билингвизм как средство межкультурного трансфера / Н.М. Азарова // Лингвистика и семиотика культурных трансферов: методы, принципы, технологии. М.: Культурная революция, 2016. С. 255–307.

35. *Зиннатова Р.*Между Арском и Карсом. // Арский муниципальный район. 15 августа 2014 г. https://arsk.tatarstan.ru/index.htm/news/328582.htm

36. *Зарипова-Четин Ч.* Взлелеявшая "сады знаний" в наших сердцах (К 70-летию профессора А.М. Саяповой) // Филология и культура. 2018. №1 (51). С. 248–251.

37. *Назипова А.* Тема женской любви в поэзии Чулпан Зариповой-Четин // Филологические науки. Вопросы теории и практики. 2014. №12 (42): в 3 ч. Ч.1. С. 134–137.

38. *Минһаҗева Л. И.* Шигъриятебездә Истанбул образы // Казан утлары. 2008. № 11. С. 140–144.

39. *Зарипова Ч. А.* Проблема демонизма в творчестве С. Рамиева в контексте восточно-европейской эстетики: автореф. дис. … канд. филол. наук: Казань, 1995. 21 с.

40. *Зиннатова Р.* Между Арском и Карсом. // Арский муниципальный район. 15 августа 2014 г. URL: https://arsk.tatarstan.ru/index.htm/news/328582.htm (дата обращения 12.10.2025.)

41. Төркиядә «вәкаләтсез вәкил» / Ч.. Зарифның Р. Сәфиуллина белән интервьюсы // http://idel-tat.ru/news/vremya-tt/trkiyadge-vkaltsez-vkil (дата обращения 01.01.2026).

42. *Алтай, Р.* Төрек илендәге татар әдәбияты илчесе. // Татарстан. 2011. № 4. 54-55 б.

43. *Загребельный П.* Роксолана. М: Сов. писатель, 1983. 639 с.

44. *Ибраһимов Г.* Көтүчеләр // https://www.antat.ru/ru/iyli/Ibragimov%20-%20130/Kotucheler.pdf (дата обращения 02.10.25)

45. *Казакова М.В.* Проблема билингвизма в поэзии А.И. Мишина 1970-1980-х гг. : автореферат дис. ... кандидата филологических наук: 10.01.02 / Казакова Мария Владимировна; [Место защиты: Институт мировой литературы им. А.М. Горького Российской академии наук]. - Москва, 2020. - 25 с.

46. *Зарипова-Четин, Ч.* Проблема демонизма в творчестве С. Рамиева в контексте восточно-европейской эстетики. Казань: «Мастер-Лайн», 2003, 175 с.

47. *Зарипова-Четин, Ч.* «Уйласам уй, сызлый күңел, сызлый җан». С. Рәмиевнең тормыш юлы һәм иҗатына карата яңа мәгълүматлар. Казан: «Яңалиф» нәшрият йорты. 2005. 202 б. (фоторәсемнәр белән).

48. *Zaripova Çetin, Ç.* Alimcan İbrahimov'un Eserlerinde Tatar, Başkurt ve Kazak Türklerinin Kültürel Değerleri. Ankara: Bengü. 2016. 369 s.

49. *Zaripova Çetin, Ç.* Alimcan İbrahimov. Âdemler. Araştırma-İnceleme-Metin. Ankara: Bengü. 2020. 169 s.

50. İshaki, A. Hikâyeler (Seçmeler). Çev. Çulpan Zaripova Çetin, Hayati Yılmaz. Muğla: Muğla Üniversitesi Yayınları. 2009. 182 s.

51. Garipov, M. Ebedi Aşk. Abdullah Tukay ile Zeytüne Mevlüdova Hikâyesi. Çev. Çulpan Zaripova Çetin, Hayati Yılmaz. Ankara: Bengü. 2016. 103 s.

52. İbrahimov, A. Seçme Eserler. Çev. Çulpan Zaripova Çetin. Ankara: Bengü. 2022. 290 s.

53. Mehdiyev, M. Turnaların İndiği Yerde. Çev. Çulpan Zaripova Çetin. Ankara: Bengü. 2025. 305 s.

54. Татджы, М. Язык любви Юнус Эмре. Жизнь и творчество. Стихотворения. Анкара: Руководство центра культуры им. Ататюрка. 2021. 133 с.

55. Караханлы, Э.З. Любовь превыше храмов. Баку: Мутерджим. 2019. 148 с.

56. Ислам через призму хадисов в 7 томах. Т. 2, 3, 4. Москва: Духовное управление мусульман Российской Федерации, 2021. 488 с.

# ИСТОКИ ФОРМИРОВАНИЯ АВТОРСКОГО БИЛИНГВИЗМА В ТВОРЧЕСКОЙ БИОГРАФИИ ЧУЛПАН ЗАРИФ

**Айзиряк Наиловна Гараева,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
aizigarai@mail.ru.

Чулпан Зариф – литературный псевдоним поэта Чулпан Афраимовны Зариповой-Четин, уроженки Арского района Республики Татарстан. Выпускница Казанского государственного педагогического университета 1992 г. является автором сборников стихотворений «Кояшка юл тота кәрваным» («Мой караван шагает к солнцу», 2003), «Апельсиновая осень» (2013), «Lacivərd Yuxular» («Синие сны», 2023). Пишет стихотворения на татарском, русском, турецком. В ее творчестве доминирует любовная лирика. Стихотворения Чулпан Зариф переводились на английский, азербайджанский, башкирский, туркменский, чувашский и другие тюркские языки. В ходе исследования выявлены факторы, способствовавшие формированию авторского билингвизма у Чулпан Зариф, художественные приемы.

**Ключевые слова:** татарская литература, Чулпан Зариф, авторский билингвизм, художественный билингвизм, двуязычие

**Для цитирования**: Гараева А. Н. Истоки формирования авторского билингвизма в творческой биографии Чулпан Зариф // Tatarica. 2026. № 1 (26). С. 71–90. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2026-26-1-71-90